# КАРАР

**19 сентябрь 2022 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Нормабаш авылында «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Нормабаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы Нормабаш авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 19 сентябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Нормабаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Нормабаш авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

-2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацны өстәргә:

- Нормабаш авылының Вахит урамнарындагы юлларга вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру

-- Нормабаш авылында, вак таш җәеп, Х.Такташ, Вахит урамнарында юллардагы чокырларны ямау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 77 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 40.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 40 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Нормабаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Нормабаш авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

-2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацны өстәргә:

- Нормабаш авылының Вахит урамнарындагы юлларга вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру

-- Нормабаш авылында, вак таш җәеп, Х.Такташ, Вахит урамнарында юллардагы чокырларны ямау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Байлар авыл җирлеге башлыгы          И.Ф. Кәримуллин